СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 3-36 от «14» ноября 2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карар нигезләмәләре Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Мамадыш муниципаль районы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://mamadysh.tatarstan.ru веб адресы буенча басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән үз көченә керә һәм 2020 нче елдан башлап һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына Мамадыш муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының бюджет, икътисадый сәясәт һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов

000107

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Советының
14.11.2019 ел, 3-36 нче санлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирүнең максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар чыгым йөкләмәләрен үтәү максатларында бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетына бирелә торган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) акчалары исәбеннән бирелә.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тора.

5. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм чыгым йөкләмәсе нигезендә билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитетка бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

6. Башка бюджетара трансфертлар билгеләнгән критерийларга җавап бирә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә.

7. Башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары булып тора:

а) әлеге Кагыйдәләрнең 15 пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү;

б) шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәү.

8. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән вакыт эчендә, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә гариза бирә.

9. Җирлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән формула буенча билгеләнә.

10. Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты белән раслана.

11. Башка бюджетара трансфертларны бирү муниципаль район Башкарма комитеты һәм вәкаләтле орган арасында Башкарма комитет тарафыннан расланган формалар нигезендә төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Килешүдә карала:

башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертларны бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең әһәмияте;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертларны бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертларны алучының билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

килешүдә каралган башка бюджетара трансфертларны алучының килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

13. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булып тора:

- Чираттагы финанс елына (Чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы карар нигезендә беркетелгән керем чыганакларына һәм бюджетара трансфертларга муниципаль район бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле чыгымнарның күләменә карата мөнәсәбәте кимендә 100 процент тәшкил иткән җирлекләр саны;

- башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан читтә түләп бетерү вакыты белән муниципаль бурыч алулар бирү елында бюджетны үтәү барышында гамәлгә ашырмаган җирлекләр саны;

Вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган хисаплылыкка үткәрелгән анализ нигезендә, нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне бәяләү Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

14. Вәкаләтле органнар килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисапны Башкарма комитетка тапшыралар.

15. Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык вәкаләтле органга йөкләнә.

16. Башка бюджетара трансфертлар Мамадыш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирлекләр бюджетларына федераль

казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен төзелгән территориаль органнары счетларына килешүдә билгеләнгән срокларда күчерелә.
17. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты керемен күчерелергә тиеш.
18. Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә муниципаль район бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш.
19. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.
20. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Мамадыш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы закон нигезендә башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тота.